# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№1** **22.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге составына керүче,
Октябрь-Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда, Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидларга 250 сум (50%) күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Октябрь-Бүләк авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Октябрь-Бүләк авылындагы Лесная урамы буенча юлларга вак таш (щебенка) җәю (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Октябрь -Бүләк авылы зиратын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Октябрь Бүләк авылында юлларны кардан чистарту.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 129 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 100 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды

1. Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге составына керүче Октябрь-Бүләк авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2020 елда, Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пункты территориясендә 1 төркем

инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидларга 250 сум (50%) күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, Октябрь-Бүләк авылында килешү буенча эш өчен түләү;;

- Октябрь-Бүләк авылында юлларны кардан чистарту;

- Октябрь-Бүләк авылында урман посадкасы территориясен койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу;;

- Октябрь-Бүләк авылы юлларына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Октябрь-Бүләк авылы, Үзәк урам, 8 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Карамалы авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Ногманов